ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2024 г. Заинск № 72

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 787 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы автомобиль юллары кулланучыларына җирле әһәмияттәге автомобиль юллары торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законга, «Россия Федерациясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2007 елның 08 ноябрендәге 257-ФЗ номерлы Федераль законга ярашлы рәвештә, Зәй муниципаль районы Уставына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 24 декабрендәге 787 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы автомобиль юллары кулланучыларына җирле әһәмияттәге автомобиль юллары торышы турында мәгълүмат бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» карарына үзгәрешләрне 3 нче пунктның 3.3.2.1 пунктчасының 11 нче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп кертергә:

«Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү гариза бирүче тарафыннан гаризаның электрон формасындагы һәр кырын тутырганнан соң башкарыла. Гаризаның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында гаризаның электрон формасындагы мәгълүмати хәбәр аша

хәбәр ителә».

2. Әлеге карарны Зәй муниципаль районының рәсми сайтында http://zainsk.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар басылып чykканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет Җитәкчесе** **Э.Э. Галеев**

Юрист

Г.Х.Никифорова